# Минем педагогик осталыгым

Укытучы! Кем генә бу исемне зур хөрмәт белән телгә алмый икән? Һәркайсыбызның иң матур хатирәләре, шатлык-борчулары, беренче дулкынланулары нәкъ менә мәктәп һәм укытучы белән бәйле.

Кыңгыраулы мәктәп еллары
Язмышым сукмаклары.
Шул елларның серле чыңлавыннан
Башланды ул хезмәт еллары.
Шул төбәктә укып кеше булдым
Татар мөгаллимәсемен
30 елдан артык гимназиядә
Армый-талмый хезмәт итәмен.

Укытучы һөнәре - чын мәгънәсендә, һөнәрләр һөнәре, барлык һөнәрләрнең анасы. Шуңа күрә бу һөнәрне сайлаган кеше гаҗәеп дәрәҗәдә тәрбияле, гыйлемле булырга тиеш. Чөнки ул баланы белеме белән генә түгел, килеш-килбәте, холык-фигыле, сөйләм әдәбе, якты йөзе, күңел пакьлеге белән дә тәрбия кыла.

Кулларымда бала язмышлары
Ап-ак биттән башлап китүләр.
Чиста күңел, сафлык-пакълек белән
Төшенчәләр бүләк итүләр

Укытучы һөнәрен җиһанга яктылык, җылылык иңдерүче кояш нурына тиңләр идем мин. Үз эшеңне яратып башкару ничек кенә авыр булмасын, ул - үзе зур бәхет. Бу тарафтан үземне бәхетле кеше дип саныйм. Шушы хезмәт еллары күз ачып йомган арада борчулары, шатлыклары белән бик тиз үтеп киттеләр. Күңелдә шатлык, горурлык хисләре уяна. Бик күп укучыларым зур тормышка аяк бастылар, туры юлдан атлап киттеләр. Минем укучыларым арасында төрле һөнәр ияләре бар. Аларның һәрберсе тормышта үз урынын тапкан икән, димәк, тырышлыгым бушка китмәгән. Укучыларымның уңышлары – ул күп еллык хезмәтем җимешләре. Әлбәттә, бернәрсә дә җиңел бирелми, күп кенә уңышлар астында зур тырышлык ята. Үзалдыңа билгеле бер максат–бурычлар куеп, шуларны тормышка ашырганда гына моңа ирешергә була. Атаклы педагог К.Д. Ушинский да: “Укытучы һәрдаим укыганда гына укытучы булып кала,” - дигән. Әйе, тырышмыйча гына укучыларга үз фәнеңне яраттырып булмый.

Туган телем – татар теле аша
Тормыш серләренә өйрәтәм,

Татарлыгым белән горурланып,
Хезмәтемнән табам бары тәм.

Замана укытучысына таләпләр катгый: бала мөстәкыйль фикер дә йөртә белсен, аны ачык итеп дәлилләсен, эшен дә дөрес оештырсын, лидерлык сыйфатлары да анда чагылыш тапсын. Шуңа күрә дәресләремдә иҗади үсеш һәм тәнкыйди фикерләү технологияләрен куллануны отышлы дип саныйм.

Төркемдә минем укучыларым, бер-берсенең уй-фикерләрен тыңлап, уртак эш башкаралар. Эш барышында алар бер-берсенә нык бәйләнгәнлекләрен аңлыйлар. Балаларым актив, аралашучан, тәнкыйтьли дә beләләр, үзләренә, иптәшләренә бәя куялар, үз фикерләрен курыкмыйча әйтәләр. Ә бит кеше ялгышларын күрә-күрә, төзәтә-төзәтә үсешкә ирешә. Балага үзен шәхес итеп тойдыру, ул эшләрдәй эшләрне, аннан башка беркем дә яхшырак эшли алмаячагына төшендерү - минем төп педагогик бурычым. “Син бит булдырасың, балам!”,- диюгә, балага канатлар үсә, ул үзүсешкә ирешә.

Олимпиада,конференция -
Сынатмый укучыларым.
Алда да язсын тоярга
Аларның уңышларын.
Аларның уңышлары
Үстерә бит мине дә.
Грантларны алу да
Дәрт өсти күңелләргә.

Методик табышларга, алгарышларга юл кечкенә уңышлардан башлана. Үз казанымда гына кайнап калмыйча, республика, Рәсәй кысаларында узган конкурсларга да укучыларымны катнаштырм һәм бик күп уңышларыбыз бар. Укучыларым К.Тинчурин сәхнәсендә чыгыш ясадылар. Аларны зур сәхнәгә чыгару киң күңеллелек, тырышлык, балаларга чиксез мәхәббәт, намуслылык сорый. Халкыбызның мәдәнияте белән таныштыру, горурлану хисләре тәрбияләү зур җиңүләргә этәрә.

Спектакльләр куюлар
Үзенә күрә бер сихәтлек.
Шуны искә алу да
Җаныма бирә рәхәтлек.
“Тормыш бусагасы”, “Тормыш җыры”
“Сүнгән йолдызлар”, “Йөрәк маем”
“Әни килде”, “Хөкем алдыннан”.
Һәрберсендә кеше язмышлары

Уйнаучылар – тоташ ялкыннан.

Төбәгемнең бөек шәхесләренә карата горурлык хисе, халкымның тарихы, гореф-гадәтләре, татар дөньясына караган милли традицияләр, халык педагогикасы аша укучыларымда телне өйрәнүгә кызыксыну, әхлакый сыйфатлар тәрбияләү максаты – мәктәп муззе оештыруга теләк уятты. Бу эшкә укучыларым, хезмәттәшләрем, ата-аналар бик теләп тартылдылар. Музейда тупланган экспонатлар дәресләрдә, ачык чараларда киң файдаланыла. Үз халкыңың тарихын белү – милли үзаңны үстерә, зиһенне баета. Эш практикамда балаларның иҗади сәләтен үстерүгә нык басым ясыйм. Матбугат битләрендә укучыларымның язмалары даими басылып тора.

Мин бүгенге көндә чиксез бәхетлемен! Аны чагыштыру дәрәҗәсе дә, үлчәү бизмәне дә юк. Янәшәмдә гаиләм, ярты сүздән аңлап төшенүче яраткан укучыларым, һәрвакыт ярдәмләшеп, фикерләшеп эшләүче хезмәттәшләрем бар.

Максатым бит минем изге эштә,
Ә мәгърифәт минем – кыйблам.
Эзем бара матур сукмак булып,
Шулай һаман алга омтылам.
Яшәвемнең шушы мәгънәсе
Бүген кала укучымда.
Шөкер итеп яши бирәм,
Рәхмәтлемен язмышыма.